КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 16 декабрь г.Казань № 1346

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре эшчәнлеге эффективлыгын һәм халыкның тормыш сыйфатын бәяләү индикаторларын раслау турында» 2022 ел, 23 март, 256 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 18 июль, 687 нче, 2022 ел, 13 сентябрь, 988 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре эшчәнлеге эффективлыгын һәм халыкның тормыш сыйфатын бәяләү индикаторларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» бүлегенең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «7. | Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнарының, сәламәтлек саклау, мәгариф, шәһәр хуҗалыгы һәм төзелеш, җәмәгать транспорты өлкәсендә җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның алар тарафыннан үзебезнең мәгълүмати-технологик карарлардан файдалануны күздә тота торган «цифрлы җитлегүе», процент[1] | еллык | х | 77,4 | х | х | х | 75,7 | 78,5 | 83,3»; |

«Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы» бүлегендә:

3 һәм 4 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «3. | Сәнәгать җитештерүе индексы, процент | ел-лык | 96,6 | 108,9 | х | х | х | 100,2 | 100,7 | 103,5 |
| 4. | Сәнәгать җитештерүенең гомуми күләмендә эшкәртү производст-восы өлеше, процент | ел-лык | 72,1 | 69,5 | х | х | х | 69,5 | 70,0 | 70,5»; |

5 пунктның 9 графасында «66,0» саннарын «40,0» саннарына алмаштырырга;
6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «6. | Ваклап сату әйләнешенең физик күләме индексы, процентлар | ел-лык | 94,2 | 107,8 | х | х | х | 93,4 | 102,4 | 104,0»; |

«Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы» бүлегенең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «3. | Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү индексы узган елның шушы чорына карата чагыш-тырма бәяләрдә, процентлар | ел-лык | 104,2 | 80,1 | х | х | х | 110,7 | 101,8 | 101,8»; |

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы» бүлегенең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2. | «Төзелеш» эшчәнлек төре буенча башкарылган эшләр күләме, узган елның тиешле чорына карата чагыштырма бәяләрдә, процент-лар | ел-лык | 96,0 | 107,8 | х | х | х | 100,0 | 100,0 | 100,0»; |

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» бүлегендә:
1 һәм 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1. | Үз статусын теркәгән үз-үзләренә эшләүчеләр өчен салым режимын кертүне исәпкә алып (һөнәри керемгә салым кулланучы индивидуаль эшкуарларны исәпкә алмыйча), мең кеше | ел-лык | 97,5 | 162,4 | х | х | х | 179,6 | 206,6 | 210,7 |
| 2. | Шәхси эшмәкәрләрне һәм үзмәшгульләрне дә кертеп, кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә мәшгульләр саны. мең кеше [1] | ел-лык | х | 772,8 | х | х | х | 796,1 | 829,2 | 845,8»; |

5 һәм 6 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «5. | Тулаем төбәк продуктның физик күләме индексы, процентлар | ел-лык | 96,9 | 103,8 | х | х | х | 100,6 | 100,8 | 103,2 |
| 6. | Тулаем төбәк продуктында төп капиталга инвестицияләр өлеше, процентлар | ел-лык | 23,4 | 20,4 | х | х | х | 18,0 | 18,4 | 18,7»; |

«Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы» бүлегенең 2 пунктындагы 2 графада «социаль-икътисадый» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм халыкның тормыш сыйфатын бәяләү индикаторлары мониторингы өчен әлеге күрсәткечләр составын һәм аларны тапшыру ешлыгын раслау турында» 2022 ел, 21 июнь, 592 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм халыкның тормыш сыйфатын бәяләү индикаторлары мониторингы өчен әлеге күрсәткечләр составына һәм аларны тапшыру ешлыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» бүлегенең 1 пунктындагы 2 графасында «млн. кеше» сүзләрен «мең кеше» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы» бүлегенең 2 пунктындагы 2 графада «социаль-икътисадый» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты» бүлегенең 1 пунктындагы 1.2 пунктчасының 4 графасында «B - кабаннарның яшәү өчен яраклы җирләр мәйданы (урман һәм кыр җирләре), мең гектар» сүзләрен «B - Татарстан Республикасы җирләренең гомуми мәйданы, мең гектар» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планын раслау турында» 2015 ел, 25 сентябрь, 707 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 26 декабрь, 989 нчы; 2019 ел, 20 июнь, 503 нче, 2019 ел, 11 декабрь, 1135 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планына «Технопарк структураларын үстерү, төбәк махсус икътисадый зоналар, Татарстан Республикасының алгарышлы үсеше территорияләрен булдыру» юлында III бүлекнең 3.2.6 пунктчасында «социаль-икътисадый» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

4. Әлеге карар (әлеге карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы егерме икенче абзацыннан һәм 2 пунктындагы өченче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин